ГОСУДАРСТВЕННАЯ
ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Большая Красная, 15/9, г. Казань,420111

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ДӘҮЛӘТ
ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ
Зур Кызыл ур. 15/9, Казан ш., 420111

тел/факс. 8 (843) 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 24

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

«05» 02 2020 ___ ел.

2019 елның 2 нче яртыеллыгы өчен гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләргә түләү күләмен үзгәртү чикләмәләрен саклау буенча дәүләт торак күзәтчелеге һәм лицензия контроле нәтиҗәләре турында хисап раслау хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 30 апрелендәге 400 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнарның түләү күләмен үзгәртү индексларын формалаштыру нигезләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 26 декабрендәге 1068 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе турында нигезләмә нигезендә боерык бирәм:

1. 2019 елның 2 нче яртыеллыгы өчен гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләргә түләү күләмен үзгәртү чикләмәләрен саклау буенча дәүләт торак күзәтчелеге һәм лицензия контроле нәтиҗәләре турында хисап (кушымтада бирелә) расларга.

2. Торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләрнең нигезле булу-булмавын тикшерү бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару өчен юлларга.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе башлыгы урынбасары С.В.Заһидуллинага йөкләргә.

Башлык С.А. Крайнов


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Кушымта

Татарстан Республикасының
Дәүләт торак инспекциясенең
05.02.2020 № 24
боерыгы белән расланды

**2019 елның 2 нче яртыеллыгы өчен гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләргә кертелә торган түләү күләмен үзгәртү чикләмәләрен саклау буенча дәүләт торак күзәтчелеге һәм лицензия контроле нәтиҗәләре турында хисап**

Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 30 апрелендәге 400 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнарның түләү күләмен үзгәртү индексларын формалаштыру нигезләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 26 декабрендәге 1068 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе турында нигезләмә нигезендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнарның түләү күләмен үзгәртү чикләмәләрен үтәү буенча торак күзәтчелеген һәм лицензия контролен Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе гамәлгә ашыра.

2019 елның икенче яртыеллыгында үткәрелгән планлы тикшерүләр барышында муниципаль берәмлекләрдә гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индексларын арттыру фактлары (алга таба – чик индекслар) ачыкланмады.

2019 елның икенче яртыеллыгында, чик индексларны арттыру фактлары предметына карата планнан тыш тикшерүләр әлеге тикшерүләрне уздыру өчен нигезләр булмавы аркасында Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан үткәрелмәде.

Документ создан в электронной форме. № 04-04/1122 от 14.02.2020. Исполнитель: Венедиктова И.А.
Страница 6 из 7. Страница создана: 14.02.2020 15:20